Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы

**КАРАРЫ**

23 гыйнвар, 2023 ел № 3

Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 80 номерлы (2017 елның 14 декабрендәге 94 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108 номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 156 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегендә җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә, кергән гариза нигезендә карар бирәм:

1. Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны билгеләргә:

- җ/к кадастр номеры 16:33:021126:452, мәйданы 916 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы, - «3.7 Шәхси торак төзелеше зонасында дини файдалану (Ж1)»,
- җ/к кадастр номеры 16:33:021126:453, мәйданы 700 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы, - «3.7 Шәхси торак төзелеше зонасында дини файдалану (Ж1)»

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елның 1 февралендә, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Питрәч ав., Совет ур., 18 нче йорт адрес буенча;

2.3. адресы буенча, авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: 422774, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородское

ур., Үзәк ур., 57Б/1 адресы буенча (дүшәмбе-җомга  8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») газетасында иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БОГОРОДСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000835